ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**______29.07.2024___________** **Чистай шәһәре** **№ ____324________**

Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «2022-2024 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында медицина кадрларын беркетү һәм аларны торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» 2022 елның 29 июнендәге 433 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясы, «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 7 пунктчасы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 29 июнендәге 433 номерлы карары белән расланган «Медицина кадрларын беркетү һәм аларны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында торак белән тәэмин итү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. Программа исемендә «2022-2024 еллар» сүзләрен «2022-2026 еллар» сүзләренә алмаштырырга.
1.2. Программа Паспортында:
“Муниципаль район бюджеты барлыгы: 3 600 000 сум, шул исәптән:
2022 ел - 178 000 сум,
2023 ел - 584 000 сум,
2024 ел - 1 494 000 сум,
2025 ел - 744 000 сум,
2026 ел - 600 000 сум.» сүзләрен

«Бөтен муниципаль район бюджеты барлыгы: 3631500 сум, шул исәптән:
2022 ел - 178 000 сум,
2023 ел - 584 000 сум,
2024 ел - 1 507 500 сум,
2025 ел - 762 000 сум,
2026 ел - 600 000 сум.» сүзләренә алмаштырырга.

1.3. 4 бүлектә:
4.1 пунктындагы 3 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
- табиб-белгечләргә торак урынны наемга (арендага/субарендага) түләү чыгымнарын ай саен 4500 сумнан артмаган күләмдә компенсацияләү;

1.4. 5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«5. Муниципаль программаны гамәлгә ашыруны ресурслар белән тәэмин итү.
Программаны гамәлгә ашыруга каралган Чистай муниципаль районы бюджеты акчалары күләме: 3631500 сум, шул исәптән:
2022 ел - 178 000 сум,
2023 ел - 584 000 сум,
2024 ел - 1 507 500 сум,
2025 ел - 762 000 сум,
2026 ел - 600 000 сум.».
Программаны финанслау чыганагы Чистай муниципаль районы бюджеты акчалары (3 нче кушымта), Чистай муниципаль районы бюджеты турындагы карар белән күрсәтелгән максатларга конкрет финанс елында каралган чикләрендә.».
1.5. 3 нче кушымтаны яңа редакциядә әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә бәян итәргә.
2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2024 елның 1 апреленнән барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru/) бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
5. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Г.Ю. Задворновага йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов

Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының карарына
3 нче кушымта
29.07.2022 ел, № 433

«2022-2026 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында медицина кадрларын беркетү һәм аларны торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын гамәлгә ашыруны ресурслар белән тәэмин итү

| № т/б | Чараның атамасы | Чыгымнарның исеме | Бюджет чараларын төп бүлүче (җаваплы башкаручы) | Финанслау чыганаклары | Финанслау күләме (мең сум) | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Барлыгы 2022-2026 елларда (мең сум) | Шул исәптән еллар буенча | | | | |
| | | | | | | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 | 2026 |
| 1 | табиб-белгечләргә торак урынын наем (арендалау) өчен түләү чыгымнарын компенсацияләү (аена дүрт мең биш йөз сумнан артык түгел) | | Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты | Муниципаль район бюджеты | 641,5 сумнарда | 178,0 | 584,0 | 1507,5,0 | 762,0 | 0 |
| 2 | матди кызыксындыру максатларында айлык түләүләр (10 мең сум күләмендә) | | Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты | Муниципаль район бюджеты | 2990,00 сумнарда | 0 | 440 | 1350 | 600 | 600 |